«Замандаш» балалар иҗтимагый оешмасы газетасы

# УһУ

Укытучылар
һәм
укучылар

N18, декабрь 2019



## Яңа ел белән, Сезне!

Бүгенге санда:

Директор сүзе.

Мәктәп директоры Гатауллина Л.Ф. -1 бит

Экологик форум: безнең уңышлар - 1 бит

Зәринә белән әңгәмә - 2 бит

Яңа ел котлаулары - 3 бит

Каләм тибрәтүчеләр иҗаты. Ахкямов Фидаил. Яңа ел мизгелләре – 4 бит

Экологик форум
“ Туган җир”



Габнасыров Ранил һәм Хаҗиева Динә,

Галимҗанова Илида

3 урынга лаек булдылар.

Уңышларыгыз белән котлыйбыз!



## Директор сүзе

Узып баручы 2019 нчы ел безнең мәктәп өчен уңышлы ел булды. Район күләмендә ясалган узган уку елы нәтиҗәләре мәктәпнең белем сыйфаты күрсәткечләре буенча I урын яулавын, тәрбия юнәлешендәге эшчәнлеге күрсәткечләре белән III урынга чыгуын күрсәтте. Укучыларыбыз республика күләмендәге конкурсларда, мәртәбәле олимпиадаларда, конференцияләрдә уңышлы чыгыш ясадылар. 2019 елның мартында Рәсәй милли проекты кысаларында ”Үсеш ноктасы” федераль гранты нигезендә информатика, тормыш иминлеге нигезләре, технология кабинетлары төзекләндерелде. Шахмат зонасы булдырылды. 821 мең сумлык ремонт ясалды. 1 млн 752 мең сумлык җиһаз кайтты. Робототехника, 3Д принтер, виртуаль чынбарлык, квадрокоптерлар укучылар файдалануына бирелде.

1 сентябрьдән без - гуманитар профильле белем үзәге. 2019 нчы елда социаль партнерларыбыз арты. Казан инженер лицее һәм аграр университет белән хезмәттәшлек итү укучыларның, укытучыларның мөмкинлекләрен үстерер дип көтәбез.

Сентябрь аенда “Уңышлы мәктәп” гранты оттык. 400 ләп мәктәп катнашкан конкурста Грантны республика буенча 8 мәктәп кенә ота алды. Алар арасында Норма урта мәктәбе булу - зур куаныч. “Уңышлы мәктәп гранты” күләме 1 млн сум. Ул укытучыларның белемен күтәрүгә тотылачак. Бүгенге көндә укучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндереп бетерә алмыйбыз әле. Мәсәлән, менталь математика, техник инглиз теле, программалаштырудан белгечләребез юк. Грант нигезендә без үзебезнең укытучыларыбызны бу белгечлекләргә әзерли алачакбыз.

Хөрмәтле укучыларыбыз, укучыларыбыз, әти-әниләребез! Бу уңышлар - сезнең тырыш хезмәтегез нәтиҗәсе. Сезгә чиксез рәхмәтемне белдерәм. Яуланган позицияләребезне югалтмыйча, бергәләп үстерә алсак иде.

Яңа елда яңа уңышлар, сәламәтлек, иминлек телим!

**Безнең интервью**





Мин, Җәләева Зәринә, Яңа ел уңаеннан тәнәфестә укучылар белән әңгәмә үткәрү теләге белән мәктәп коридорына чыгарга кузгалдым. Кабинет бусагасында ук 8 б сыйныфыннан Хабибуллин Айназ белән маңгайга – маңгай чүт бәрелешмәдек. Бу очрактан файдаланып калырга уйладым һәм аңа сорау бирдем:

- Сәлам, Айназ! Кыш бабайга ышанасынмы?
- Сәлам! Әйе, әлбәттә ышанам!
-Синдә Яна ел кәефе бармы соң инде?
- Әлегә юк, булыр дип көтәм.
- Айназ, ә син 2020 нче елдан нәрсә көтәсең?
- Уңышлы ел булуын көтәм.
- Нинди уңыш?
- Сер!

Химия кабинетында 11 сыйныфтан Шарипжанов Ильяс ямансулап утыра иде:



- Ильяс, сәлам! 2019 нчы ел сиңа нинди вакыйгалар белән истәлекле булды?
- Сәлам, Зәринә! Район күләмендә КВН да катнаштык. Без аңа бик озак әзерләндек,1 нче урында калдык. Минем өчен бу бик мөһим иде, чөнки уземне шул юнәлештә тикшереп карадым. “Ак калфак” семинарында мәдәни чарада катнаштым, анда да үземне сынап карадым.
- Ильяс, син Кыш бабайга ышанасынмы?
- Әлбәттә, ышанам!
- Ә син Кыш бабайдан нинди бүләкләр көтәсең?
- Тәк.., 2020 нче елның 28 майларында физикадан 80 балл җыйсам, Кыш бабайдан иң зур бүләк шул булыр иде.

Ильяс шулай хыялланып калды.Мин алга таба киттем. Мәктәптә иң нәниләр - беренчеләр янына килдем.1 а сыйныфыннан Юнысов Рамазанга сүз каттым:



- Рамазан, син Яңа ел бәйрәмен көтәсеңме?
- Бик көтәм.
- Кыш бабайның чын булуына ышанасыңмы?
- Әйе, ышанам!
- Кыш бабайдан бүләккә нәрсә сорадың?
- Пультлы машина сорадым.

Менә безнең укучыларда шундый уйлар, фикерләр, теләкләр. Әле тагын сорашырга була иде, дәрескә чакырып, кыңгырау шалтырады. Йөгердем дәрескә, калганы икенче санда булыр инде.

## Яңа ел теләкләре







Хөрмәтле 1 нче сыйныф укучылары һәм әти-әниләр! Без 2019 нчы елда укырга өйрәндек. 2020 нче елдан белем үрләрен яулый башларбыз! Сезне яңа 2020 ел белән котлыйбыз! Сезгә нык сәламәтлек, бары тик куанычлар гына телибез!

Йөзләрегез һәрчак көләч булсын, һәр туган конегез имин, тыныч булсын!

1нче сыйныф укытучылары: Хасанова Р.Ф.,

Хөрмәтле, Резеда Накиповна !

Сезне чын күңелдән Яна ел белән тәбрик итәм. Сезгә бу ел көтелмәгән шатлыклар, борчу-мәшәкатьсез гаилә иминлеге алып килсен! Сезгә сәламәтлек, бәхет телим!

Укучыгыз Шагидова Зөһрә

2019 нчы ел мәшәкатьле һәм уңышлы булды. Бу безнең бөтен коллектив өчен дә, укучылар үзидарәсе өчен дә шулай булгандыр. Эшләмичә генә уңышларга ирешеп булмый бит.

Мине иң куандырганы - актив укучылар артуы, укучылар узидарәсенең көчле команда булып өлгереп житүе. Кызыксынучан, актив, битараф булмаган, мәктәп тормышында үзенең дә өлеше булырга тиеш дип санаган, авырлыклардан курыкмаучы укучылар тупланган биредә. Алар кушканны гына эшләүче түгел. Үз идеяләре, хыяллары, максатлары, планнары, бар. Һәм бу хыялларны тормышка ашыручыны читтән көтми, үзләре эшләргә янып торалар. Нинди генә чара уздырасы булмасын, Гөлсинә Рашитовна белән минем таянырлык көчле команда бар. Бу Гөлсинә Рашитовна һәм шушы укучыларның сыйныф житәкчеләре хезмәте нәтижәсе.

Яңа 2020 нче ел ел барыбызга да шатлык-куанычлар, укуыбызда, эшебездә уңышлар алып килсен. Бердәм булыйк!

Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары: Шалаева Г.С.

Х сыйныф укучыларына!

Кадерле укучыларым, сезне чын күңелемнән якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйм!Сезнең күңелләрегезгә, йөрәкләрегезгә яхшы өмет салырдай, хыялларыгызга яңа юллар ачырдай сихри бәйрәм телим!Бу яңа елның үзенең күңелле вакыйгалары зур җиңүләре, яңа уңышлары белән исегездә калуын, сәламәт, бәхетле, бердәм булуыгызны, яңа елда яңа идеяләр, кызыксынулар белән януыгызны телим. Юлыгызда үзегез төсле яхшы кешеләр генә очрасын.. Мин сезнең белән горурланам һәм дә сезне бик яратам!

Галиева Р.А.

## Яңа ел бәйрәме мизгелләре



### Каләм тибрәтүчеләр иҗаты

**Тәмле чәй**

Буген кызыл кар явачак
Чөнки мин иртә тордым.
Чәй эчәсе килә иде,
Юлны кухняга бордым.
Телефонны алдым кулга,
Берәр сәгать утырдым.
Шулай язышa-язышa
Чәй эчәргә онытттым.
Мин чәй ясап эчкәндә
Инде сәгать ун тулган.
Телефонга карый-карый,
Дөньям да онытылган.
Тәмле чәйләрне эчкәч,
Мин урамга ашыктым,
Киендем дә чыгып чаптым.
Кичкә кадәр уйнап туйгач,
Карга батып, хәлдән тайгач,
Өйгә керергә ашкындым,
Жылы чәй эчәргә булдым
Килеп утырдым өстәлгә,
Телефонны алдым кулга.
Дуслардан хатлар килгән,
Тотындым язышырга.
Төнгә кадәр телефонымны
Кулдан ычкындырмадым.
Йокы алдыннан ярамас дип
Чәй дә эчеп тормадым.
Инде төн уртасы житкән,
Яттым да мин йокладым .
Ә икенче көнгә торгач,
Чәй эчәргә уйладым…









Ахкямов Фидаил, 10 сыйныф укучысы.

Редколлегия: Зарипова Д., Җәләева З., Гаязова Н.